ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙО-
НЫ
МӘСӘДЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШ-
КАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ
423753,Мәсәде авылы,
Нефтяников ур.,18нче йорт
Тел.3-44-49.
e-mail: masad.akt@yandex.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ МАСАДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬ-
НОГО РАЙОНА
423753,деревня Масады,
ул.Нефтяников,дом 18,
тел.3-44-49.
e-mail: masad.akt@yandex.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**15 гыйнвар 2026 ел** **№4**

**Адреслаштыру объектына адрес бирү, мондый адресны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 29 сентябрендәге 776 номерлы «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәреш кертү турында» һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын юкка чыгару турында»гы карары белән кертелгән үзгәрешләрне гамәлгә ашыру максатында, Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Адреслаштыру объектына адрес бирү, мондый адресны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге башкарма комитетының 2025 елның 9 июлендәге 13 номерлы «Адреслаштыру объектына адрес бирү, мондый адресны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарын юкка чыгарырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Актаныш муниципаль районы
Мәсәде авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе И.Т.Гатин

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Мәсәде авыл җирлеге башкарма
комитеты 15 гыйнвар 2026 ел №4
карарына кушымта

**Адреслаштыру объектына адрес бирү, мондый адресны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба - Регламент) адреслаштыру объектына адрес бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын һәм тәртибен, мондый адресны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару (алга таба - муниципаль хезмәт) стандартын һәм тәртибен билгели.

2. Муниципаль хезмәт алучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба-мөрәҗәгать итүче).

Адреслаштыру объектына адрес бирү турында яисә аның адресын гамәлдән чыгару турында гариза (алга таба - гариза) адреслашу объекты милекчесе тарафыннан үз инициативасы белән яки адреслашу объектына түбәндәге хокукларның берсенә ия зат тарафыннан бирелә:

а) хуҗалык алып бару хокукы;

б) оператив идарә итү хокукы;

в) гомерлек мирас итеп алу хокукы;

г) даими (сроксыз) файдалану хокукы.

Гариза бирүчеләр мәнфәгатьләрен гариза бирүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә вәкаләтләр тапшырылган затлар һәм физик затларның законлы вәкилләре (алга таба – гариза бирүче вәкиле) яклый ала.

Күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре исеменнән гариза белән Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән милекчеләрнең гомуми җыелышы карары белән мондый гариза бирергә вәкаләтле шундый милекчеләрнең вәкиле мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бакчачылык яки яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәте әгъзалары исеменнән гариза белән мөрәҗәгать итү хокукына, әлеге ширкәт әгъзаларының гомуми җыелышы карары белән гариза бирүгә вәкаләтле вәкил ия.

Әлеге пунктта күрсәтелгән зат исеменнән «Кадастр эшчәнлеге турында» Федераль законның 35 статьясында яисә 42.3 статьясында каралган документ нигезендә адреслаштыру объекты булган тиешле күчемсез милек объектына карата кадастр эшләрен яисә комплекслы кадастр эшләрен башкаручы кадастр инженеры мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3. Муниципаль хезмәт мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүченең категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелергә тиеш, алар «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» (алга таба – Бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

## II. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

Муниципаль хезмәт атамасы

4. Адреслаштыру объектына адрес бирү, үзгәртү һәм андый адресны гамәлдән чыгару.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган исеме

5. Муниципаль хезмәтне Мәсәде авыл җирлеге Башкарма комитеты күрсәтә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе

6. Гариза бирүче «Адреслашу объекты адресын бирү, үзгәртү яки гамәлдән чыгару» өчен мөрәҗәгать иткәндә, муниципаль хезмәт нәтиҗәләре булып тора:

1) адреслашу объектына адрес бирү, үзгәртү яки гамәлдән чыгару турында карар (5 нче кушымта) дәүләт адрес реестрыннан өземтә белән бергә;

2) муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карар (6 нчы кушымта).

Адреслашу объектына яңа адрес бирелгән очракта адреслашу объекты адресын гамәлдән чыгару турында карар бу объектка яңа адрес бирү турында карар белән берләштерелергә мөмкин.

Реестрга белешмәләр кертү «Дәүләт адреслы реестрында, дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында, физик һәм юридик затларга, шул исәптән федераль мәгълүмат адреслы системасына керү мөмкинлеген тәэмин итү юлы белән, белешмәләр бирү тәртибе, ысуллары һәм рәвешләре турында» Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2020 елның 14 сентябрендәге 193н номерлы боерыгына 2 нче кушымта нигезендә рәсмиләштерелә торган дәүләт адреслы реестрыннан тиешле өземтә белән раслана.

7. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә Башкарма комитетның (яки Башкарма комитетның) вазифаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә Бердәм портал, Республика порталы яки адрес системасы порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.

8. Шулай ук, мөрәҗәгать итүче сайлавы буенча, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүче алырга мөмкин:

– Башкарма комитетта электрон документ формасында, кәгазь чыганакта бастырылган;

– күпфункцияле үзәктә Башкарма комитет тарафыннан юлланган электрон документның күпфункцияле үзәк мөһере һәм күпфункцияле үзәк хезмәткәре имзасы белән расланган, кәгазь чыганакта бастырылган нөсхәсе формасында.

9. Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе гамәлдә булган вакыт дәвамында электрон документ формасында яки электрон документның кәгазь чыганактагы нөсхәсе формасында алырга хокуклы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты

10. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты:

а) гариза кәгазь чыганакта тапшырылган очракта - гариза кергән көннән башлап 10 эш көненнән артмаган вакыт эчендә;

б) гариза электрон документ формасында тапшырылган очракта - гариза кергән көннән башлап 5 эш көненнән артмаган вакыт эчендә;

11. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

12. Электрон документ рәвешендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документны җибәрү муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

13. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итүдән баш тарту карары түбәндәге нигезләрдә кабул ителә:

1) Регламентның 3 нче кушымтасына ярашлы рәвештә гариза бирүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә бирелергә тиешле документларны тапшырмау яки каршылыклы мәгълүмат булган документлар тапшыру.

2) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алынган законлы вәкилләр турында мәгълүматны расламау, гариза бирүче исеменнән гаризаның (мөрәҗәгатьнең) моңа вәкаләте булмаган зат тарафыннан тапшырылуы;

3) документларны тиешле булмаган органга тапшыру;

4) дөрес булмаган һәм (яисә) каршылыклы белешмәләр, килешенмәгән төзәтмәләр, аларның эчтәлегеннән берсүзсез аңлатырга мөмкинлек бирми торган җитди зарарланулар булган документларны, үз көчен югалткан документларны тапшыру;

5) Регламентның 3 нче кушымтасына ярашлы муниципаль хезмәт алучы булып тормаган затның муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүе;

6) электрон гаризаның мәҗбүри кырларын дөрес тутырмау (дөрес булмаган, тулы булмаган яки, әлеге Регламентта билгеләнгән таләпләргә туры килмәү), электрон гаризада һәм тәкъдим ителгән документларда каршылыклы мәгълүматлар булу;

7) электрон формадагы гаризаның (мөрәҗәгатьнең) һәм башка документларның, гамәлдәге законнарны бозып, электрон имзадан файдаланып имзалануы.

14. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

15. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар түбәндәге нигезләр буенча кабул ителә:

1) ведомствоара хезмәттәшлек нәтиҗәсендә соратып алынган җавапта адреслашу объектына адрес бирү яисә аның адресын гамәлдән чыгару өчен кирәкле документның яисә мәгълүматның булмавы, һәм тиешле документның гариза бирүче (гариза бирүче вәкиле) тарафыннан аның теләге буенча тапшырылмавы;

2) гариза бирүче инициативасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны кире алу;

3) адреслашу объектына адрес бирү яисә аның адресын гамәлдән чыгару өчен кирәк булган һәм аларны тапшыру бурычы гариза бирүчегә (гариза бирүче вәкиле) йөкләнгән документларның Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртипне бозып бирелүе;

4) адреслашу объектына адрес бирү яисә аның адресын гамәлдән чыгару өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 19.11.2014 № 1221 карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләренең 5, 8 - 11 һәм 14 - 18 пунктларында күрсәтелгән очраклары һәм шартлары булмау.

16. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре, гариза бирүченең категориясен (билгеләрен) исәпкә алып муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту нигезләре Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

17. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен түләү алу Россия Федерациясе законнары белән каралмаган.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

18. Муниципаль хезмәт алуга гариза биргәндә көтү вакыты - 15 минуттан артык түгел.

19. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Мөрәҗәгатҗ итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы мөрәҗәгатен теркәү вакыты

20. КФҮ шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирелгән көнне гариза бирүчегә КФҮ АИС гаризаның җибәрелгәнлеген раслаучы теркәлү номеры һәм гариза бирелгән дата белән расписка бирелә.

21. Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы яки адрес системасы порталы аша җибәргәндә, гариза бирүче гариза биргән көнне Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гаризаның җибәрелүен раслый торган, гаризаны теркәү номеры һәм гариза бирү көне күрсәтелгән хәбәрнамә ала.

22. Гариза бирелгән көнне Башкарма комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә Башкарма комитетның вәкаләтле вазыйфаи заты гаризаны кабул итү датасын һәм аңа кушып бирелгән документларны күрсәтеп, ике нөсхәдә мөрәҗәгать итүчегә бер нөсхә кире кайтарыла.

Муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган биналарга таләпләр

23. Муниципаль хезмәт янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм урыннарда күрсәтелә.

Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннары документлар тутыру өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

24. Инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керү максатыннан түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге (биналарга/биналарга керү/чыгу һәм алар чикләрендә уңайлы хәрәкәт итү );

2) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән урыннарда урнаштырылган визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат;

3) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясенең тотрыклы бозылуы булган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

4) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, мондый объектларга керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшерү, шул исәптән кресло-колясканы файдаланып;

5) инвалидларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат саклагычларын тиешенчә урнаштыру;

6) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язмаларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайльнең рельефлы-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау;

7) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

8) озата баручы этне махсус өйрәтүне раслый торган һәм форма буенча һәм тәртиптә бирелә торган документ булганда кертү, алар Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Озата баручы этне махсус өйрәтүне раслый торган

документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында»22.06.2015 №386н боерыгы белән билгеләнгән.

25. Муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган объектлардан һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр 01.07.2016 елдан соң файдалануга тапшырылган яки модернизацияләнгән, реконструкцияләнгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

26. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр турындагы мәгълүмат Башкарма комитетның, КФҮнең рәсми сайтында, шулай ук бердәм һәм Республика порталларында урнаштырыла.

Муниципаль хезмәтнең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре

27. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән файдалану күрсәткечләре булып:

Документлар кабул ителә торган бинаның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;

мәгълүмат стендларында, муниципаль районның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга хезмәтләрдән башкалар белән тигез дәрәҗәдә файдаланырга комачаулый торган каршылыкларны узуда ярдәм итү.

28. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып:

1) документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;

2) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу вакытын үтәү;

3) Башкарма комитет хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;

4) мөрәҗәгать итүченең вазифаи затлар белән хезмәттәшлеге саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

4.1) муниципаль хезмәт күрсәтү барышында гариза һәм барлык кирәкле документларны тапшырганда гариза бирүче күпфункцияле үзәк хезмәткәрләре белән бер тапкыр аралаша;

4.2) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен күпфункцияле үзәктә электрон документның кәгазь нөсхәсе рәвешендә алу кирәк булган очракта – бер тапкыр.

Хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер хезмәттәшлек итү вакыты 15 минуттан артмый.

Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын кучмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Бердәм порталдан, Республика порталыннан, терминал җайланмаларыннан файдаланып бәяләргә хокуклы.

29. Мөрәҗәгать итүчеләрнең ихтыяҗларына туры килү-килмәү хезмәтен тикшерү карар белән билгеләнгән кире элемтәне анализлау нигезендә даими үткәрелә.

Хезмәт күрсәтү процессларын оптимизацияләү, гариза бирүчеләрнең хезмәт күрсәтү процессыннан канәгать булу дәрәҗәсе тотрыклы рәвештә кимегән очракта (өч айдан артык дәвамында) үткәрелә.

Хезмәт күрсәтү процессыннан канәгать булу дәрәҗәсе кимемәгән очракта, оптимизация биш елга бер тапкырдан да сирәгрәк үткәрелми.

30. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы һәм статусы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталдагы шәхси кабинетта яисә Республика порталында, күп функцияле үзәктә алынырга мөмкин.

31. Муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүче сайлаган теләсә кайсы КФҮ аның яшәү урынына яисә фактта яшәү (булу) урынына бәйсез рәвештә экстерриториаль принцип буенча башкарыла.

32. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәтне комплекслы гарызнамә составында алырга хокуклы.

33. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре турында мәгълүмат Башкарма комитетның рәсми сайтында, КФҮдә, шулай ук Бердәм һәм Республика порталларында урнаштырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтүгә башка таләпләр

34. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче:

а) Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүматтан файдаланырга;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон образлары элегрәк 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) Муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон рәвештә бирелгән гаризаларны үтәүнең барышы һәм статусы турында белешмәләр алырга;

г) муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын Бердәм портал, Республика порталы ярдәмендә бәяләргә;

д) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә алырга;

е) Башкарма комитетның, шулай ук аның вазифаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Бердәм портал, Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазифаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан башкарылган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларына) судка кадәр шикаять бирү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять бирергә.

35. Гаризаны формалаштыру Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән, өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада гариза бирү кирәклегеннән башка гамәлгә ашырыла.

36. Мөрәҗәгать итүчеләрнең КФҮгә (алга таба - язма) кабул итүгә язылуы Бердәм, Республика порталы, КФҮ контакт-үзәге телефоны аша башкарыла.

Мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә кабул итү өчен теләсә кайсы буш датага һәм вакытка язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер көнгә язылу әлеге көн башланырга бер тәүлек кала тәмамлана.

Бердәм портал, Республика порталы аша алдан язылу өчен гариза бирүчегә система тарафыннан соратыла торган мәгълүматларны күрсәтү зарур, шул исәптән:

фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта);

телефон номеры;

электрон почта адресы (теләк буенча);

теләгән дата һәм кабул итү вакыты.

Мөрәҗәгать итүче алдан язылганда хәбәр иткән белешмәләр мөрәҗәгать итүченең шәхсән кабул иткәндә тапшырган документларына туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылып куйганда мөрәҗәгать итүчегә талон-раслауны бастырып чыгару мөмкинлеге тәэмин ителә. Мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын хәбәр иткән

очракта, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат, кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, күрсәтелгән адреска җибәрелә.

Алдан язылуны башкарганда мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның билгеләнгән кабул итү вакытыннан 15 минут узгач, ул килмәгән очракта гамәлдән чыгарылуы турында мәҗбүри рәвештә хәбәр ителә.

Гариза бирүче алдан язылу вакытыннан теләсә кайсы вакытта баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләү һәм аутентификацияләү үтүдән, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен кирәкле вакыт аралыгын исәпләү өчен тиешле белешмәләрне тапшырудан тыш, гариза бирүчедән башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

Муниципаль хезмәт күрсәтүгә кирәкле документларның тулы исемлеге

37. Регламентның № 3 кушымтасындагы таблицада муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге китерелгән, алар түбәндәгечә бүленә:

а) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга тиешле документлар;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы документлар.

38. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар формалары турында мәгълүмат әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән.

## III. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары

Административ процедуралар исемлеге

39. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза һәм документлар кабул итү;

2) ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеш;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

4) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек

40. Муниципаль хезмәт алу өчен түбәндәге ведомствоара мәгълүмати сорауларны федераль дәүләт мәгълүмати системасы «Ведомствоара электрон үзара бәйләнешнең Бердәм системасы» аша юллау кирәк:

1) Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар (күчемсез милек объектының төп характеристикалары һәм теркәлгән хокуклары турында мәгълүматлар)» мәгълүмати соравы. Әлеге мәгълүмати сорау «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте»нә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән башлап 1 эш көне эчендә юллана. «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте» соралган мәгълүматларны ведомствоара сорау юлланганнан соң 1 эш көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә бирә.

2) Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә» мәгълүмати соравы. Күрсәтелгән мәгълүмати сорау «Федераль салым хезмәтенә» муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән башлап 1 эш көне эчендә җибәрелә. «Федераль салым хезмәте» соралган мәгълүматларны ведомствоара сорау

җибәрелгәннән соң 2 эш көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә бирә. Сорау юридик зат хезмәт күрсәтүне сораган очракта башкарыла;

3) Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә» мәгълүмати соравы. Күрсәтелгән мәгълүмати сорау «Федераль салым хезмәтенә» муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән башлап 1 эш көне эчендә җибәрелә. «Федераль салым хезмәте» соралган мәгълүматларны ведомствоара сорау җибәрелгәннән соң 2 эш көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә бирә. Сорау шәхси эшмәкәр хезмәт күрсәтүне сораган очракта башкарыла.

41. Муниципаль хезмәт алу өчен түбәндәге ведомствоара мәгълүмати сорауларны башка сервислар аша җибәрү кирәк:

1) Мәгълүмати сорау «Гариза бирүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ». Әлеге мәгълүмати сорау «Гражданлык хәле актларының бердәм дәүләт реестры» яки «Дәүләт социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы» хезмәте аша 1 эш көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә гамәлгә ашырыла, гариза бирүченең вәкиле хезмәт күрсәтүне сораган очракта;

2) «Ышанычлылык бирү һәм аның эчтәлеге турында белешмәләр» мәгълүмат гарызнамәсе. Күрсәтелгән мәгълүмати гарызнамә «Нотариатның бердәм мәгълүмат системасы» сервисы ярдәмендә 2 эш көненнән дә артык булмаган вакытта гамәлгә ашырыла;

3) мәгълүмати сорау «Адреслашу объектының кадастр планы яки тиешле территориянең кадастр картасында урнашу схемасы». Әлеге мәгълүмати сорау Башкарма комитетның структур бүлекчәсеннән 2 эш көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә сорала;

4) мәгълүмати сорау «Адреслашу объекты төзелешенә рөхсәт (төзелеп килүче адреслаштыру объектларына адрес бирү өчен) һәм (яки) адреслашу объектын эксплуатациягә кертүгә рөхсәт (эксплуатациягә кертелгән адреслаштыру объектларына адрес бирү өчен)». Әлеге мәгълүмати сорау Башкарма комитетның структур бүлекчәсеннән 2 эш көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә сорала;

5) мәгълүмати сорау «Торак бинаны торак булмаган бинага яки торак булмаган бинаны торак бинага әйләндерү турында җирле үзидарә органы карары». Әлеге мәгълүмати сорау Башкарма комитетның структур бүлекчәсеннән 2 эш көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә сорала;

6) мәгълүмати сорау «Кабул итү комиссиясе тарафыннан яңадан төзү (яңадан планлаштыру) тәмамланган акт (адреслаштыру объектларының бер яки күбрәк яңа объектлары барлыкка килүгә китерүче яңадан төзү һәм (яки) яңадан планлаштыру очрагында)». Әлеге мәгълүмати сорау Башкарма комитетның структур бүлекчәсеннән 2 эш көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә сорала;

7) «Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында теркәлергә тиеш булмаган муниципаль мөлкәт, җир кишәрлеге бирүгә шартнамә турында белешмәләр» мәгълүмати соравы. Күрсәтелгән мәгълүмати сорау Башкарма комитетның структур бүлекчәсеннән 2 эш көненнән дә соңга калмыйча соратыла.

## IV.Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гарызнамәне карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысуллары

42. Техник мөмкинлек булганда, гариза бирүче аның хезмәт күрсәтү соравының статусын үзгәртү турында хәбәр ителә, бу регламент белән билгеләнгән (хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү турында; гариза һәм документлар җыелмасын карау турында; хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү турында), шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге этабында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы адымнар һәм гамәлләр турында, түбәндәге ысулларның берсе белән:

смс-мәгълүмат бирү юлы белән;
- Бердәм портал ярдәмендә;
- Республика порталы ярдәмендә;
башка сервислар һәм ысуллар ярдәмендә (булган очракта).

1 кушымта

## ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР ҺӘМ КЫСКАРТЫЛМАЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) – Республика порталы;
2. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru/) – Бердәм портал;
3. Федераль дәүләт мәгълүмат системасы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең федераль реестры» (http://frgu3.gosuslugi.ru) Реестр);
4. Мәсәде авыл җирлеге Башкарма комитеты– Башкарма комитет;
5. Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе – КФҮ.
6. Федераль адреслы мәгълүмат системасы (https://fias.nalog.ru/) – адреслы система порталы.

2 нче кушымта

**Гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары**

| № т/б | Хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе | Гариза бирүченең аерым билгесе атамасы | Гариза бирүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | Адреслашу объектына адрес бирү яисә аны гамәлдән чыгару турындагы карар | Адреслашу объектының милекчесе булган физик зат | 1А |
| 2. | | Адреслашу объектының милекчесе булган юридик зат | 2А |
| 3. | | Адреслашу объектының милекчесе булган шәхси эшмәкәр | 3А |
| 4. | | Хуҗалык алып бару хокукында адреслашу объектына ия физик зат | 4А |
| 5. | | Хуҗалык алып бару хокукында адреслашу объектына ия юридик зат | 5А |
| 6. | | Хуҗалык алып бару хокукында адреслашу объектына ия шәхси эшмәкәр | 6А |
| 7. | | Адреслашу объектына оператив идарә хокукында ия булган физик зат | 7А |
| 8. | | Адреслашу объектына оператив идарә хокукында ия булган юридик зат | 8А |
| 9. | | Адреслашу объектына оператив идарә хокукында ия булган шәхси эшмәкәр | 9А |
| 10. | | Гомерлеккә мирас итеп биләү хокукында адреслашу объектына ия физик зат | 10А |
| 11. | | Гомерлеккә мирас итеп биләү хокукында адреслашу объектына ия юридик зат | 11А |
| 12. | | Гомерлеккә мирас итеп биләү хокукында адреслашу объектына ия шәхси эшмәкәр | 12А |
| 13. | | Адреслашу объектына даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында ия булган физик зат | 13А |
| 14. | | Адреслашу объектына даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында ия булган юридик зат | 14А |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 15. | | Адреслашу объектына даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында ия булган шәхси эшмәкәр | 15А |
| 16. | | «Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясында яки 42.3 статьясында каралган документ нигезендә адреслашу объекты булган тиешле күчемсез милек объектына карата кадастр эшләрен яки комплекслы кадастр эшләрен башкаручы кадастр инженеры | 16А |
| 17. | | Гариза бирүче вәкиле | 17А |

3 кушымта

**Муниципаль хезмәт күрсәтүгә кирәкле документларның тулы исемлеге**

| № т/б | Идентификатор | Гариза бирүче тарафыннан бирелә торган документлар төрләрен ачыклау | Бирү ысулы |
|---|---|---|---|
| *Мөрәҗәгать итүче хезмәт күрсәтү өчен үзе тапшырырга тиешле документлар* | | | |
| 1. | 1А-17А | Гариза | Бердәм портал, Республика порталы, адреслы система порталы, "Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре 2.0" мобиль кушымтасы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 2. | 1А-17А | Шәхесне таныклаучы документ | Бердәм портал, Республика порталы, адреслы система порталы, "Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре 2.0" мобиль кушымтасы, Башкарма |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | комитет, КФҮ |
| 3. | 17А | Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ | Адреслы система порталы, "Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре 2.0" мобиль кушымтасы, Башкарма комитет, КФҮ |
